| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Чукмарлинского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Чукмарлы авыл җирлеге советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

№16 14 декабрь 2020 ел

Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 4 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең сайлаулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү кагыйдәләрен раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Чукмарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 4 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә» нең 1 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлекле 6,7,8 пунктлар өстәргә:

«6. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның еллык түләүле отпускы төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусктан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле ялның озынлыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль вазыйфа, муниципаль хезмәт вазыйфасы, шулай ук дәүләт вазыйфасы һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы ел саен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Ел саен бирелә торган төп түләүле отпуск һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 45 календарь көненнән дә артмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат ының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы Рәисе И.Х.Хадиуллин